ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 апрель 2018ел

№ 1996

Яр Чаллы шәһәренең «Титан» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктына, шәһәр Уставының 41 маддәсенә, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәнең 5 пунктына, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезнамәгә туры китереп

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Титан» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастыруны һәм «Интернет» челтәрендә рәсми сайтта урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 11 апрелендәге
1996 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«Титан» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Чаңгыларны прокатка бирү   14 яшьтән зуррак балалар, зурлар | сум/сәгать | 150,00 |
| 2. | Чаңгыларны прокатка бирү   14 яшькә кадәрге балалар | сум/сәгать | 75,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова